ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

15.12.2025 г. Казань № 539-115/тэ-2025

Азнакай муниципаль районының Актүбә ш.т.п. кулланучыларга «Әлмәт җылылык челтәрләре» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2026-2028 елларга тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 15.12.2025 ел, № 32-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Азнакай муниципаль районының Актүбә ш.т.п. кулланучыларга «Әлмәт җылылык челтәрләре» (алга таба – «Әлмәт җылылык челтәрләре» АҖ) акционерлык җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2028 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 2026-2028 елларга билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулын кулланып тарифлар формалаштыру өчен җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2025 № 539-115/тэ-2025
карарына 1 нче кушымта

# «Әлмәт җылылык челтәрләре» АҖ тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2026-2028 елларга календарь буенча бүлгәләнгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Кискен һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Азнакай муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | Актүбә ш.т.п. «Әлмәт җылылык челтәрләре» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 2 255,95 | - | - | - | - | - |
| | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 2 553,76 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 2 553,76 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 3 903,08 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 3 203,08 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 3 340,52 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән) <*> | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 2 752,26 | - | - | - | - | - |
| | | 01.10.2026 | 3 115,59 | - | - | - | - | - |

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Кискен һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | | башлап 31.12.2026 кадәр | | | | | | |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 3 115,59 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 4 761,76 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 3 907,76 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 4 075,43 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының
15.12.2025 № 539-115/тэ-2025
карарына 2 нче кушымта

## Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2026-2030 елларга җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрлары

<table>
<tr><th rowspan="3">т/с</th><th rowspan="3">Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы</th><th rowspan="3">Ел</th><th rowspan="2">Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе</th><th rowspan="2">Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы</th><th colspan="3">Энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</th></tr>
<tr><th>Ягулыкның чагыштырма сарыфы</th><th>Җылылык челтәренең матди характеристикасына технологик югалтулар күләменең мөнәсәбәте</th><th>Технологик югалтулар</th></tr>
<tr><th>мең сум</th><th>%</th><th>шартлы ягулык кг/Гкал</th><th>Гкал/м$^2$</th><th>Гкал</th></tr>
<tr><td colspan="8">Азнакай муниципаль районы</td></tr>
<tr><td rowspan="3">1</td><td rowspan="3">«Әлмәт җылылык челтәрләре» АҖ</td><td>2026</td><td>16 345,11</td><td>1</td><td>152,00</td><td>0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>X</td><td>1</td><td>152,00</td><td>0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2028</td><td>X</td><td>1</td><td>152,00</td><td>0</td><td>-</td></tr>
</table>

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге